КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 сентябрь г.Казань № 699

2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турында, 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты хакында

2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турындагы, 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты хакындагы докладларны тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрларын хупларга.

2. 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразын, 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын исәпкә алырга.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына 2025 елның 30 сентябренә кадәр «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын, әлеге закон проекты белән бер үк вакытта

тапшырыла торган документларны һәм материалларны теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга билгеләнгән тәртиптә кертергә.

4. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына 2025 елның 30 сентябренә кадәр «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга билгеләнгән тәртиптә кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин